Яр Чаллы (Россия Федерациясе Татарстан Республикасы) һәм Kazan (Төркия Республикасы) шәһәрләре арасында дуслык мөнәсәбәтләре урнаштыру ниятләре турында
КИЛЕШҮ

Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре һәм Kazan шәһәре (Төркия Республикасы), шәһәрләр арасындагы үзара аңлашу һәм дуслыкның мөһим роль уйнавын истә тотып, гражданнарның үзара эшчәнлек һәм хезмәттәшлеккә, ике яклы мөнәсәбәтләрне ныгыту омтылышына таянып, түбәндәге мәсьәләләрдә үзара аңлашуларга ирешелде:

1. Ике яклы килешүләрне исәпкә алып, алга таба Яклар дип исемләнгән Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре һәм Kazan шәһәре (Төркия Республикасы), дуслык мөнәсәбәтләре урнаштыру ниятләрен раслыйлар.

2. Яклар икътисадый үсеш һәм хезмәттәшлек итү бизнесы мәсьәләләре буенча тәҗрибә, мәгълүмат уртаклашу юлы белән хезмәттәшлек итүгә кызыксынуларын белдерәләр. Яклар шулай ук уртак инвестиция проектларын тормышка ашыруда катнашу ниятләрен раслыйлар.

3. Яклар шәһәрләрнең икътисадый, фәнни-техник һәм мәдәни потенциалы белән танышу өчен делегацияләр алмашу инициативасын хуплыйлар.

4. Конструктив хезмәттәшлекне үстерү һәм ике яклы мөнәсәбәтләрне ныгыту максатында, Яклар дуслык мөнәсәбәтләре урнаштыру турында Килешүгә кул кую мәсьәләсе буенча регуляр диалогны хуплаячаклар.

5. Әлеге Килешү, аңа Яклар кул куйган көннән башлап өч ел эчендә гамәлдә кала һәм Якларның берсе, әлеге Килешүнең гамәлдә булуын туктату нияте барлыгы турында чираттагы вакытның срогы тулганчы 180 көн алдан язмача рәвештә хәбәр итмәгән булса, Килешү һәрвакыт автомат рәвештә алдагы өч еллык срокка кадәр озайтылачак.

6. Әлеге Килешү 2015 елның 11 июнендә Яр Чаллы шәһәрендә ике нөсхәдә, һәркайсы рус һәм төрек телләрендә имзаланды, шул ук вакытта барлык текстлар да бер үк көчкә ия.

Татарстан Республикасы
Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты Җитәкчесе
(имза куелган) Н.Г. Мәһдиев

Kazan Мэры
(Төркия Республикасы)
(имза куелган) Локман Эртюк